ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.03.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 576**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2021 елның 23 июнендәге 1420 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 февралендәге 92 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2021 елның 23 июнендәге 1420 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 6 пункттагы 5 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$O_{tiq}$ - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының "Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында " 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакына чыгымнар.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2021 елның 23 июнендәге 1420 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмасын финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"

$$FOSC^t_{ivxyz} = \sum^{n_9}\left(m_{vz\lim} \times k_{mi\,vxyz} \times g_{i\,vxyz} \times \left(NFZ^t_{vz} + \left(NSV^t_{vxyz} - C_{xyzpit}\right)\right) + C_{xyzpit} \times m_{ivxyx} - RP^t_{vxyz} \times \left(m_{ivxyz} - m^{100\%}_{ivxyz}\right) - RP^t_{vxyz} \times 0{,}5 \times m^{50\%}_{ivxyz}\right) +$$

$$+NSI^t_{vi} + K^t_{iv} + Tr_i + FOSC_{ozzo},$$

2.2 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

" $FOSC_{oazo}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасы объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтүгә финанс белән тәэмин итү күләме";

2.3 түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Мәктәпкәчә белем бүрү оешмасы объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтүгә финанс белән тәэмин итү күләме $(FOSC_{oazo})$ түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$FOSC_{oazo} = N_{oazo} \times P_{oazo} \times 12 \times D_g ,$$

биредә:

$N_{oazo}$ - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр хакының нормативлары;

$P_{oazo}$ - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән саклау постлары саны;

12 - көненә эш сәгатьләре саны;

$D_g$ - елга көннәр саны".

3. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев